КЫТАЙГА ЮЛ
Казан янә халыкара форумга әзерләнә

> 2

АВЫЛДА – ТЫНЛЫК
Татарстанда кәҗә-сарыклар саны кимегән

> 2

МӨГАЛЛИМНӘР НӘСЕЛЕ
450 еллык хезмәт стажы булган Захаровлар тормышларын мәктәптән башка күз алдына китерми

> 3

KARAKUZ-2023
«Татнефть» Әлмәтне кабаттан этно-модерн үзәккә әйләндерде

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 118 (29085) | Чәршәмбе | 16 август | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Яшәргә өйрәнәбез

ҮЗ КУЫШЫҢ КАДЕРЛЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казанда яшәүче Гыйльмуллиннар гаиләсе 2021 елның декабрендә социаль ипотека буенча фатир алу өчен чиратка баса. Бер ел да үтми, ике бүлмәле фатирларында өй туе уздырырга насыйп була аларга. «Торырга фатирыбыз бар иде үзе, алай тиз булыр дип уйламадык та», – ди Динара ханым.

Гыйльмуллиннарның «Яшь гаилә» социаль ипотека программасы буенча алынган фатирлары «Салават Күпере» микрорайонындагы «Сандугач» торак комплексында урнашкан.

– Ипотеканы 15 елга алдык. Беренче взносны ничек булдыра алдык, шулай түләгән идек. Шуңа да без башкалар белән чагыштырганда бераз күбрәк – ай саен 17 мең сум түлибез, – дип сөйләде Динара Шәйдуллина-Гыйльмуллина.

Фатирларында бераз ремонт ясап, тәрәзәләрне алыштырырга кирәк булган.

– Җил керә иде чөнки. Хәер, андый гына кимчелекләр теләсә кайсы фатирда бар инде ул. Аның каравы безнең ишегалды бик яхшы. Машиналар кермәгәч, балалар өчен җаның тыныч. Балалар бакчасы, мәктәп тә якында гына, – ди хуҗабикә.

Фатир бәяләре артудан туктамаган чорда, яшьләргә мондый мөмкинлектән файдаланырга киңәш итә ул.

Тагын нәрсә?

Гомумән алганда, Татарстанда яшьләрнең торак шартларын яхшырту өлкәсендә дүрт программа гамәлгә ашырыла.

1 «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында»гы Татарстан законы (15 елга торак бәясеннән 60 процентка кадәр процентсыз соңрак түләү мөмкинлеге (рассрочка);

2 «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы (торак бәясеннән 35 процент субсидия);

3 «Яшь гаилә» социаль ипотека программасы (7 процент ставкалы ташламалы ипотека);

4 «Студентлар лигасы» уздыра торган торак конкурсы (ел саен 49 кешегә социаль ипотека буенча фатир алу мөмкинлеге бирелә).

*2018 елдан бирле шушы дүрт программа **2874** яшь гаиләгә торак шартларын яхшыртырга ярдәм иткән. Моның өчен барлыгы **689,2** млн сум акча тотылган.*

Дүрт юнәлеш арасында иң популяры – «Яшь гаилә» социаль ипотекасы. 2020 елдан бирле җәмгысы 3726 гаилә чиратка басып, шуларның 2027се елына нибары 7 процент ставкалы ипотека буенча торак сатып алган.

– Әлеге программа Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәмендә Татарстан Дәүләт торак фонды белән берлектә гамәлгә ашырыла. «Яшь гаилә» программасында катнашуның тагын бер өстенлекле ягы – гаиләдә туган һәр бала өчен фатир бәясеннән 200 мең сум акча чигерелә, – дип сөйләде Татарстанның яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков шул уңайдан Министрлар Кабинетында оештырылган брифингта.

Дәүләт торак фондының башкарма директоры урынбасары Булат Гыйльманов әйтүенчә, июль аеннан Татарстанда социаль ипотека буенча алынган фатирга түләү өчен ана капиталын да файдаланырга мөмкин (моңарчы мондый мөмкинлек юк иде. – **Авт.**).

– Моннан тыш, әгәр яшь гаилә башка банкта тагын да кулайрак ипотека ставкасы таба икән, бездә рефинанслау каралган. Ягъни без тәкъдим итә торган 7 процентлы ставканы тагын да киметү мөмкинлеге бар, – дип сөйләде ул.

«Яшь гаилә» социаль ипотека программасы ярдәмендә фатир алучылар саны буенча Казан – беренче урында. Өч ел эчендә башкалада яшәүче 1352 яшь гаилә үз фатирларына күченгән. Моннан тыш, Түбән Камада – 282, Чаллыда 238 яшь гаилә өй туе уздырган. 2023 елда тагын өч меңгә якын гаиләне тораклы итү өчен 160,6 мең кв. м торак төзергә ниятлиләр. Әйтик, Казанда яшьләр өчен фатирлар «Салават Күпере» һәм «М14» микрорайоннарында төзеләчәк. Шунысын искәртик: бу фатирлар «кер дә яшә» кагыйдәсе буенча төзелә башлаган икән. Ягъни аларда яшәү өчен кирәкле барлык техника да була. Хактан да, кер дә яшә инде менә!

Дәүләт торак фонды «Яшь гаилә» программасы буенча сатыла торган фатир бәяләрен торак базарындагы уртача бәяләр белән чагыштырды:

Шәһәр	Социаль ипотека (1 кв. м өчен*)	Торак базары (1 кв. м өчен)
Казан	75000	138182
Чаллы	58000	88146
Әлмәт	70000	119754
Түбән Кама	50500	85345

сумнарда

Ахыры 2 нче биттә >

Юлларда – балалар

Татарстанда балигъ булмаган балалар катнашында юл-транспорт һәлакәтләре ешайган. Соңгы берничә көндә шундый ике авария (Лаеш һәм Лениногорск районнарында) теркәлгән. Бу хакта республиканың Дәүләт автоинспекциясеннән хәбәр иттеләр.

ЮХИДИ идарәсе вәкилләре ата-аналарны балаларына күз-колак булырга өнди. Аларга рульгә утырырга рөхсәт итмәскә, автомобиль ачкычларын бирмәскә кирәк, дип кисәтәләр.

Шуны да искәртик: Татарстанда ел башыннан 233 юл-транспорт һәлакәте булган. Аварияләрдә 8 бала гомере өзелгән, 250се төрле җәрәхәтләр алган.

Чигенмәс чир

Татарстанда коронавирус йоктырып, хастаханәгә эләгүчеләр саны арта. «Реальное время» интернет-басмасы ачыклаганча, соңгы атнада хастаханәгә 23 кеше эләккән. Бу узган атнадагы саннан 9,5 процентка күбрәк.

Россия күләмендәге саннар да коронавирус йоктыручылар саны арту хакында сөйли. Әйтик, узган атнадагы күрсәткеч белән чагыштырганда, бу атнада чирләүчеләр саны 1,9 процентка арткан. Федераль оператив штаб 7–13 август аралыгында 972 кешенең чирләве турында хәбәр иткән иде. Шушы ук чорда чирләп терелүчеләр саны 2933 кеше булган. Хастаханәдә дәваланучылар илнең 38 төбәгендә күбәйгән.

Балың баллымы?

Сыйфатлы да, тәмле дә. Роскачество белгечләре Татарстан балын сыйфатлы һәм куркынычсыз дип тапкан.

Идарә вәкилләре Башкортстан, Алтай, Краснодар крае, Татарстан, Орел өлкәсе һәм Мәскәү ярминкәләрендә тәкъдим ителгән балны тикшергән. Нәтиҗә буларак, Татарстан, Мәскәү һәм Барнаул балларын сыйфатлы дип таныганнар, ә Краснодар крае, Орел өлкәсенекендә фруктоза белән глюкозаның тиешле микъдарда булмавы ачыкланган. Белгечләр, Башкортстан балы да сыйфат таләпләренә туры килми, дигән нәтиҗә чыгарган.

Сүз уңаеннан, Федерация Советының Аграр азык-төлек сәясәте һәм табигатьтән файдалану комитеты рәисенең беренче урынбасары Сергей Митин сүзләренчә, Россия базарында булган балның 70 проценты Роскачество таләпләренә туры килми. Сенатор фикеренчә, күп очракта алыпсатарлар кулына эләккән бал сыйфатын югалта, чөнки алар балга төрле кушылмалар өсти.

Вазгыять

Саклап тотасы түгел таратасы

ӨТЕРНЕ КАЯ КУЯРГА?

Белгечләр кулланучылар чыгымнары (товар, хезмәт һәм җәмәгать туклануына тотыла торган акча күләме) артуын әйтә. Халык маяга дип туплаган акчасына да кул суза башлаган ди хәтта.

Бу елның алты аенда Татарстанда 635 млрд сумлык товар сатылган. Шуның яртысыннан артыгы (53 проценты) азык-төлек булмаган товарларга туры килгән. Бу – 338 млрд сум дигән сүз. Җәмәгать туклануында да үсеш. Сәүдә әйләнеше биредә 20,6 процентка артып, 32 млрд сумга җиткән.

Элегрәк артык акчасын сарыф итәргә базмаган халыкның болай җанлануына нәрсә этәргән соң?

Иң беренче чиратта, бу халыкның реаль керемнәре һәм хезмәт хакы артуга бәйле. Реаль керем белән керем арасында аерма бар. Икенчесе – кешенең билгеле бер вакыт аралыгында алган акчасы ул. Пенсия, хезмәт хакы, дивидендлар, кертемнәрдән процентлар, стипендия. Башкача аны «номиналь керем» диләр. Реаль дигәне исә – төрле чорда бер үк суммага сатып алырга мөмкин булган товарлар һәм хезмәтләрнең санына тигез күрсәткеч.

Язганны сан белән раслыйк. Татарстанстат мәгълүматларына караганда, республикада агымдагы елның гыйнвар – май айларында хезмәт хакы буенча үсеш 10,8 процентны тәшкил иткән. Ил күләмендә бу күрсәткеч – 6 процент.

Банклар да тырыша. Июль аенда алар физик затларга 1,53 трлн сумлык кредит рәсмиләштергән. Бер ай элек булган күрсәткечтән – 4,65 процентка, бер ел элек булган саннан 1,8 мәртәбә күбрәк.

Ләйсән ХАЛИКОВА, финанс белгече:
– Бер яктан караганда, бу, чынлап та, кешенең кереме артуга бәйле. Күпмедер дәрәҗәдә хезмәт хакы арту күзәтелде. Әмма бөтен кешене бер казанга саласы килми. Кайсыдыр оешмаларда хезмәт хакы элеккечә калырга мөмкин. Арту ул әле шундук, бермә-бер, сизелерлек итеп арту дигән сүз дә түгел. Кешенең хезмәт хакы 1 мең сумга артты ди, моңа карап кына ул патшаларча яши башламый бит әле.
Аннан, без бит икътисад базарындагы кайсы тармакларда бәя ничек үзгәргәнен күрәбез. Иң элек бу – җәмәгать туклануы, азык-төлек сатып алу. Кешенең күп акчасын шушылар «ашый». Башка нәрсәне алмый тору да мөмкин, әмма кешенең һәрвакыт ашыйсы киләчәк.
Паника да кимеде. Чикләүләр шартларында яшәү дә үз көен ала. Параллель импорт, үзебездә җитештерү барлыкка килә, дигәндәй.
Күп кенә гаиләләрдәге ир-атлар махсус хәрби операциядә килешү буенча катнаша. Анда да түләүләр каралган. Гаиләләргә матди ярдәм бар. Бу да статистикага тәэсир итми калмый.
Ни дисәләр дә, кеше акчаны янга калдыру ягын кайгырта. Хезмәт хакы нинди булуга карамастан. Кеше зур супермаркетларга йөрмичә, эконом-классны кибетләргә бара. Бу начар түгел. Теге яисә бу товар андый кибеттә арзанрак икән, нишләп бу мөмкинлектән файдаланмаска? Янга калган акчаны маяга калдыру була.
Киләчәккә фараз дигәндә, моңа берәү дә төгәл җавап бирә алмас. Доллар кыйммәтләнде дип, бәя арттыручылар табылачак. Акча күп, дип кенә булмый, һәркем кесәсенә карап, керем-чыгымнарын барларга тиеш.

Сүзгә-сүз

Максим ТОПИЛИН, Россия Дәүләт Думасының Икътисадый сәясәт буенча комитеты җитәкчесе:

Вейплар һәм аларга охшаш никотинлы продукция аз өйрәнелгән. Әмма күп кенә белгечләр аларны гади тәмәке белән бер дәрәҗәдә зыянлы дип саный.

(Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгында фикер алышканда сөйләгәннәрдән)

ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЛӘРЕ – ИНТЕРНЕТТА

Соңгы мәгълүматлар буенча, Россиядә яшәүчеләрнең 71 проценты Дәүләт хезмәтләре порталыннан файдалана. Порталга нинди тармакка бәйле сораулар белән ешрак мөрәҗәгать итәләр?

Сәламәтлек саклау..........60%
Салым..........51%
ЮХИДИ һәм МВД..........35%
Торак-коммуналь хуҗалык..........26%

*Росстатның 2022 елгы нәтиҗәләре буенча

Качып котылам, димә

Бу җәйдә Татарстанда, шул исәптән Казанда да шөпшәләрнең активлыгы күзәтелә. Белгечләр моның сәбәбен атады.

«Кышын ана бөҗәкләр генә йоклый. Алар майда оя кора, йомырка сала һәм шуннан соң аларның саны арта башлый. Иң күп артым августка туры килә. Бу вакытта диаметры 3–4 см гына булган ояның зурлыгы 30–40 сантиметрга кадәр җитәргә мөмкин», – ди Казан федераль университетының зоология һәм гомуми биология кафедрасы доценты Николай Шулаев.

Галим әйтүенчә, шөпшә баллы әйберләр ярата һәм хәзер актив рәвештә кортларга (личинкага) ашарга эзли.

«Алар сок савытларына да керергә мөмкин. Әгәр шөпшә кешене чакса яки кеше ялгыш кына аны йотып җибәрсә, бу бик куркыныч, – дип кисәтә белгеч. – Шуңа күрә, әгәр берәр җирдә шөпшә оясын күрәсез икән, аннан китүегез хәерле булыр. Кулларны болгап, аларны куарга тырышу яхшыга илтмәс. Шөпшәләр кешене йөгергән вакытта да чага ала».



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ПСИХИК СӘЛАМӘТЛЕК КРИЗИСЫ

Кешелек дөньясы бүген финанс-икътисад кыенлыкларыннан гына түгел, туры мәгънәсендә психиканың какшавыннан интегә. ЛГБТ-җәмәгатьчелекнең планетакүләм диктатура урнаштырырга омтылуын, тиктомалдан балаларның җенесен алыштыруның эпидемиягә әверелеп баруын, адәм балаларының, акылдан язган кебек, түли алмаслык әҗәтләр туплап, байлык җыярга омтылуларын бары тик психиканың нормадан массакүләм рәвештә җитди тайпылышлар кичерүе белән генә аңлатып була.

Үткән атнада төрек матбугаты Истанбул университеты галимнәре һәм табибларының балаларга җенси үсешне туктата торган препаратлар бирүләре һәм үсмерләргә җенесне алыштыру буенча операцияләр ясаулары турында шаулады. Аннан алда гына әлеге университет академиклары, ЛГБТ активистлары һәм психиатрлары җенесне алыштыруга бәйле күмәк фәнни хезмәт бастырган булганнар. Игътибар итик: Төркия – рәсми рәвештә ЛГБТга һәм җенесне алыштыру шаукымына каршы көрәш алып барган сирәк илләрнең берсе. Шуңа карамастан, планетакүләм барган саташу – гейлар һәм лесбиянкаларның үз хакимлекләрен урнаштыруга омтылышы анда да актив бара.

Төрек профессоры Зәки Байрактар илдә, законнарны һәм медицина принципларын бозып, балаларның җенесен алыштыру операцияләре ясаучы үзәкләр һәм табиблар барлыгын әйтә. Югарыда искә алынган фәнни хезмәттә генә дә 22 балага гормональ блокаторлар бирелүе һәм 7 балага җенесне алыштыру операцияләре ясалуы турында мәгълүматлар табылуын да белдерә ул. Профессор моңа кагылышы булган академиклар һәм табибларны хөкемгә тартуны таләп итә. Төрек законнары җенесне алыштыру операцияләрен 19 яшьтән соң гына һәм белгечләр комитеты хуплаганда гына үткәрергә рөхсәт итә.

ЛГБТ-җәмәгатьчелекне нормага әйләндерү һәм аңа өстенлекләр бирү шаукымы исә бөтен Җир шарында төп сәясәткә әверелеп бара. Сербия Президенты Вучич, «алсу»лар һәм «зәңгәр»ләрне яклый торган кануннар кабул итүне таләп итеп, Евросоюз тарафыннан үзенә көчле басым ясалуын әйтә. Бөтендөнья банкы әле соңгы көннәрдә генә, ЛГБТга каршы закон кабул иткән өчен, Угандага кредит бирүне туктатты. Күп кенә илләрдә банклар (арада элекке совет республикалары да бар) ЛГБТга каршы сүз әйтүчеләрнең банк хисапларын бикли. Шул ук вакытта җенси тайпылышларны байрак итеп күтәрүче илләрдә адәм балаларының үз-үзләренә кул салу очраклары кискен арта. Америкада 2022 елда 50 меңләп кеше дөньядан шул ысул белән киткән. «Ун американың тугызы, Америка психик сәламәтлек кризисы кичерә, дип саный», – диелә илнең Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр министрлыгы белдерүендә.

Россиядә

ДОЛЛАРНЫ ТӨП СТАВКА БЕЛӘН БОГАУЛАУ

Дүшәмбе көнне долларның, сумны изеп-таптап, югарыга омтылуы рәсми даирәләрдә ризасызлык тудырды. Җомгада 99 лы санда туктап калган курс яңа атнаның беренче сәгатьләрендә үк башта 100 сумлык чикне узды, аннан 101 һәм 102 дигән саннарны да бик җиңел яулады. Илдә реаль инфляция куркынычы гына түгел, икътисадның кайбер тармакларында җимерелү хәвефе дә туа башлады. Үзәк банкның, Финанс министрлыгының һәм, гомумән, хөкүмәтнең пассивлыгын тәнкыйтьләгән рәсми белдерүләр күренде. Россия Президентының киңәшчесе Максим Орешкин ТАССка: «Сум көпшәкләнүенең төп сәбәбе – йомшак акча-кредит сәясәте, Үзәк банк вазгыятьне нормага китерүнең бөтен инструментларына ия», – дип, белдерү ясады. Сум фундаменталь сәбәпләр нигезендә очсызлана, Үзәк банк берни дә эшли алмаячак дип фаразлаган белгечләр тавышы да ишетелде. Вазгыять катлаулы иде. Путинның һәрбер чыгышында диярлек Россия икътисадының тотрыклы үсеше турындагы оптимистик белдерүләрен шик астына ала торган хәл туды. Бәяләр бәйдән ычкынса, халыкны телегипноз белән генә тынычландырып булмаска мөмкин иде. Ил икътисады өчен кыенлыклар да вәгъдә итә сумның зәгыйфьләнүе. Чит илдән килеп эшләүчеләрнең өчтән бере кайтып китәчәк, дигән шомлы хәбәрләр күренде. Җирле халык мөһаҗирләрне яратмаса да, һәркем аңлый: алардан башка икътисад арбасын тартып бару кыенлашачак. Бигрәк тә төзелеш тармагы авыр хәлдә калачак.

Үзәк банктагылар да тиз уянды. Төштән соң ук инде сишәмбе көнне Үзәк банкның чираттан тыш утырышы уздырыласы игълан ителде. Чираттагы утырыш сентябрь уртасында гына буласы иде, бер айга алга күчерергә туры килде. Төп ставка күтәреләчәк. Дүшәмбедә үк инде моңа беркем дә шикләнмәде, чөнки Үзәк банк кулында ике генә корал бар: валюта базарына долларлар белән чыгу һәм процент ставкасын югарыга үрләтү. Соңгысын сизелерлек күтәрергә туры киләчәк иде. 8,5 процентган 10 процентка кадәр сикерүне фаразладылар. Рәсми белдерү белән бергә үк сум курсы да күтәрелә башлады. Сишәмбедә иртәнге сәгать 10.30да рәсми белдерү булырга тиеш иде һәм ставканың 12 процентка җиткерелүе турында белдерү алынды да.

Югары төп ставка шулай ук икътисадка куркыныч тудыра: икътисадый активлыкның һәм җитештерүнең кимүен вәгъдә итә. Әмма доллар курсыннан аермалы буларак, аның нәтиҗәләре күпкә соңрак һәм салмаграк күренәчәк. Ә валюта курсы тотрыклану гарантиясен биреп бетерә алмый ул барыбер.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

КЫТАЙЛАРГА... ТАТАР КУНАКЧЫЛЛЫГЫ!

КАЗАНДА «РОСТКИ» ХАЛЫКАРА ФОРУМЫНЫҢ ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ

Кунакларга – уңайлы, катнашучыларга файдалы булсын. Казан янә халыкара форумга әзерләнә. Сентябрьдә булачак «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара хезмәттәшлек» форумына әзерлек һәм аны оештыру комитетының утырышы узды.

tatarstan.ru

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, Кытай Россиянең стратегик партнеры санала. «Төп максат – форумны югары дәрәҗәдә оештыру, Татарстанның мөмкинлекләрен һәм аның нинди булуын күрсәтү», – диде ул утырышта.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, чит ил кунакларына уңайлы булсын өчен, барысын да эшләргә кирәк. Моңа барысы да керә: виза, таможня эше, аэропортта каршы алу, кунакханәләргә урнаштыру, иминлекне тәэмин итү. Рөстәм Миңнеханов бу юнәлешләрдә эшне көчәйтергә кушты.

– Бу – җитди чара. Барлык сорауларны да хәл итәргә кирәк, – диде Рәис.

Хәер, Татарстанның халыкара дәрәҗәдәге чараларны оештыру тәҗрибәсе бар. Моны Рөстәм Миңнеханов та телгә алды.

Оештыру комитетын җитәкләгән Алексей Песошин сүзләренә караганда, бүген ике ил арасында хезмәттәшлек барлык юнәлешләр буенча, шул исәптән төбәк дәрәҗәсендә дә үсеш алган. Шуларның иң мөһимнәре – нефть химиясе продукциясе, югары технологияләр, Кытай компанияләрен махсус икътисадый зоналарга җәлеп итү.

Кытай Халык Республикасының Казандагы генераль консулы Сян Бо сүзләренчә, әлеге җитди форумны уздыру ике арадагы мөнәсәбәтләрне үстерүдә мөһим роль уйнаячак. Провинцияләрне форумда катнашырга чакыруларын да әйтте.

Сан

2022 ел нәтиҗәләре буенча, Татарстан белән Кытай арасында товар әйләнеше **58** процентка артты һәм **1,6** млрд долларны тәшкил итте.

ФОРУМ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

- Форумның исеме («РОСТКИ») Россия (Рос), Татарстан (Т) һәм Кытай (Ки) сүзләреннән алынган.
- Форумны оештыру тәкъдиме белән Татарстан чыккан иде.
- «РОСТКИ» форумы **2023** елның **7–8** сентябрь көннәрендә узачак. Төп мәйданчык – «Казан Экспо» күргәзмәләр үзәге.
- Форумда **3** меңләп кеше катнашыр дип көтелә. Әлеге чарада төрле юнәлешләр буенча **40**ка якын эшлекле сессияләр оештыру ниятләнә.
- Әлеге форумда кече һәм урта бизнес вәкилләренә Кытай базарына чыгу, ике арадагы хезмәттәшлекне ныгыту, логистика мәсьәләләренә басым ясалачак.

Юбилейга – бүләк

Безнекеләрне бел!

Татарстан Рәисе Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров Казан Кремлендә стендка ату буенча Россия чемпионаты һәм беренчелеге җиңүчеләре, пуля белән ату буенча БДБ илләре уеннары җиңүчеләре белән очрашты.

Билгеле булганча, быел «Динамо» бөтенроссия физкультура-спорт җәмгыятенә 100 ел тулды. Юбилей елында Татарстан спортчылары яңа уңышлары белән сөендерә.

Беренче яртыеллык нәтиҗәләренә генә карыйк: стендка һәм пуля белән ату федерациясе спортчылары хисабында 49 медаль бар. 32 медальне (шуларның 11е – алтын) – стендка ату белән шөгыльләнүчеләр, 17сен (9ы – алтын) пуля белән атучы спортчылар яулаган.

– Яхшы сезон белән куандырдыгыз. Татарстан спортчылары илкүләм ярышларда да, халыкара чараларда да катнаша. Спортчыларның казанышлары – тренерларның яхшы эше нәтиҗәсе дә ул, – диде Әсгать Сәфәров.

Аның сүзләренчә, яңа үрләр яулау һәм күнекмәләрне арттыру өчен республикада барлык шартлар да бар.

– Шактый эш башкарылган, алда – яңа бурычлар. Тренировкаларда тырышырга, җиңүләр яулап, ил һәм республиканы тагын да данларга кирәк, – дип, спортчыларга уңышлар теләде ул.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Бу атнаның дүшәмбесе тетрәндергеч фаҗига белән тәмамланды. Махачкаладагы ягулык салу станцияләренең берсендә көчле шартлау булган. Баштарак янәшәдәге автосервиста янгын чыккан. Ул тиз арада ягулык салу станциясенә күчкән. Шартлауда 35 кешенең гомере өзелгән, 105 кеше зыян күргән. 15 август Дагыстанда матәм көне дип игълан ителде.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Дагыстан башлыгы Сергей Меликовка кайгы уртаклашу телеграммасы юллады.

«Татарстанда Махачкала читендәге автоягулык станциясендә шартлау вакытында күпсанлы корбаннар булу турындагы хәбәрне тирән кайгы белән кабул иттеләр. Республикада яшәүчеләр исеменнән, шәхсән үз исемемнән иң якын һәм кадерле кешеләрен утта югалтканнарның кайгысын уртаклашам. Тугандаш Дагыстан халкы белән бу фаҗига кайгысын уртаклашабыз, кайгы килгән гаиләләрнең нык булуын, зыян күрүчеләрнең тизрәк савыгып тернәкләнүләрен телибез», – диелә Татарстан Рәисе юллаган телеграммада.

Үз куышың кадерле

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Районнарга да кирәк

«Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасына килгәндә, аның нигезендә яшь гаиләләргә торак бәясенең 30 проценты (баласыз гаиләләргә) яки 35 проценты (балалы гаиләләргә) күләмендә бушлай субсидия бирелә. Быел әлеге программа өчен республика бюджетыннан 100 млн сум бүленеп бирелгән (чагыштыру өчен: моңарчы 50 млн иде). Моңа әле 26 млн сум күләмендәге федераль акча да өстәлә.

– Без яшьләрне торак белән тәэмин итү өлкәсендә районнарга игътибар бирергә тырышабыз. Яшьләрне районнарда калдырасы иде бит. Әлеге программага килгәндә, 2018 елда ул нибары 18 районны колачласа, быел барлык районнарда да эшли. Әмма яшьләрнең торак шартларын яхшырту өлкәсендә эшләп җиткермәгән районнар бар. Актаныш, Әтнә, Чүпрәле, Алабуга, Кайбыч, Лаеш, Менделеевск һәм Тукай районнарында эшне көчәйтергә кирәк, – дип искәртте Ринат Садыйков.

P.S. Россия Үзәк банкының төп ставканы кисәк кенә 12 процентка күтәрүе фатир бәяләренә дә йогынты ясамый калмас. Шуңа да яңа гына аякка басып килүче яшь гаиләләргә дәүләт күрсәтә торган ярдәм чаралары турында искә төшерү беребезгә дә комачауламас.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ЯРДӘМ ЧАРАЛАРЫННАН ФАЙДАЛАНУ ШАРТЛАРЫ VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Авыл хуҗалыгы

Татарстанда сарыклар, кәҗәләр һәм дуңгызлар саны кимегән. Татарстанстат мәгълүматлары буенча, республикада 341,2 мең сарык һәм кәҗә исәпләнә. Бу – узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, 2,4 процентка кимрәк дигән сүз.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТЫН УРАМНАР

Авылларда сарык саны кимүне иң нык сизүчеләр – итек басучылардыр, мөгаен. Хәер, алары да хәзер бармак белән генә санарлык калып бара. Зур Кукмара авылында яшәүче Рәмзия Галимҗанованың күңел сандыгы бер авылдан берничә көн йон җыйган вакытларны да хәтерли әле.

– Без озак еллар итек басабыз инде, – ди ул. – Моннан 10–15 ел элек авылда һәр хуҗалык диярлек сарык асрый иде. Хәзер аларның саны кимегәннән-кими. Сарык малын тотуның файдасын күрмибез, диләр. Элек зур авылларда өчәр-дүртәр көн йон җыя торган идек, хәзер бер сәгатьтә эшебез тәмам да була. Алардан да йонны 3–5 кг гына алып чыгабыз. Ә бит элек капка саен ук булмаса да, күпчелек хуҗалыклардан 10–20шәр килограмм йон белән кайта идек. Моннан тыш, ни өчендер хәзер сарыклар бәтине дә берне-икене генә китерә башлады бит. Бишәр-алтышарны китергән чаклары артта калды.

Актаныш районының Күҗәкә авыл җирлеге элек-электән сарык асраучылары белән билгеле булган. Күҗәкә авылында да, Адай, Югары һәм Түбән Уръяды авылларында да сарыкчылык белән уңышлы кәсеп иткәннәр. Өлкән буын Югары Уръяды авылында сарык фермасының гөрләп эшләгән чакларын да хәтерлидер. Яшь һәм урта буын да озак еллар бу төр малларны асрап көн иткән әле. Тик соңгы елларда бу якларда да сарыкчылык башлыча фермерлар шөгыле генә булып калган.

– Элек бездә генә түгел, районның бөтен авылында да күпләп асрадылар сарыкны, хәзер берән-сәрән генә хуҗалыкта асрыйлар. Фермерларда һәм тагын берничә кешедә генә бар, – ди Күҗәкә авылыннан Нәфисә Гаязова. – Авыл бетүнең сәбәпләре нинди, сарыкныкы да шундый. Беренчедән, авыл картайды. Элек сарык, сыер асрап көн иткән буын олыгайды, китеп барды. Көтү дә хәзер я чират белән көтелә, я электр көтүче куела. Ә чират белән көтүне барлык кеше дә булдыра алмый. Акча түләп көттерүгә калгач, файдасы бөтенләй калмый.

Нәфисә Гаязова әйтүенчә, күпчелек кеше сарыкны файдасы булмаганга бетерә. Йонын сатып булмый, итен дә бөтен кеше яратып бетерми, ди ул.

– Бәлки күпләп асраган очракта файдасы бардыр да. Шашлык өчен яхшы бит аның ите. Корбанлыкка да күпләп килеп алалар дип беләм. Ә болай гади халык өчен аның мәшәкатеннән башкасы юк, – диде ул.

Арча районында яшәүче Галимҗан Абдуллин да, кигән киемнәрдә синтетика өстенлек итү сарык йонын, бу төр мал асрауны кысрыклап чыгарды, дигән фикерен җиткерде.

– Күпчелегебез синтетикага күчте бит, – ди ул. – Совет заманында армиягә тун тегәләр иде. Сарыкның тиресе дә кирәк чаклар булды. Ул елларда сарык асрау отышлы иде. Элек халык йон белән бергә иттән дә табыш алса, хәзер итеннән генә бераз акча эшли ала. Гадәттә Корбан бәйрәмнәрендә саталар сарыкларны. Бер сарык сатып, кулга якынча 10 мең сум акча керә, дигән сүз.

Сарыклар белән бергә кәҗәләр дә кимегән хуҗалыкларда. Кайберәүләр: «Кәҗә дә булдымы мал?» – дип көлемсерәп кенә кырын караш ташлаганда, озак еллар хуҗалыкларында кәҗә асраган Халидә һәм Илсум Ибраһимовлар әлеге төр мал тотуны сыерга караганда да отышлырак ди.

– Без сыерын да, кәҗәсен дә асрап карадык. Сыер асрау күпкә чыгымлырак чыга. Аңа печәнен дә, ашлыгын да, сенажын да, башкасын да әзерләргә кирәк, – ди ул. – Безнең якларда берара халык эре мал асрарга җае калмагач, кәҗәгә күчә башлаган иде. Чөнки аны тоту җиңелрәк, сөте дә файдалырак. Хәзер инде кәҗәсе дә, сыеры да калмады диярлек.

Авылда кешесе калмагач, кем тотсын инде аларны? Мал бетә дип аптырыйсы юк инде, кешесе беткәч, анысы да булмас. Без әле көтү кайткандагы гөр килеп торган урамнарны да хәтерлибез. Хәзер кичке якта да авыл урамнары тып-тын.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ГОД ПЕДАГОГА И НАСТАВНИКА 2023 УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ

ТУГРЫЛЫК

УКЫТУЧЫ ЗАХАРОВЛАР ДИНАСТИЯСЕ МӘКТӘП ДИП ЯШИ

Алабугада яшәүче укытучы Захаровлар династиясенең хезмәт стажы – 450 елдан артык. Әлеге нәсел 13 укытучыны берләштерә, бүген шуларның дүртесе укыта. Берсе дә бу юлны сайлаганына үкенмәгән. Алар яратуны буыннан-буынга ничек күчерә алды икән?

rais.tatarstan.ru

Захаровлар тормышны укытучылыктан башка күз алдына китерә алмый. «Оныклар да, әлеге һөнәрне сайлап, безне сөендерсен иде», – диләр.

Алабуга районы Олы Шүрнәк авылында яшәүче Василий бабалары укытучы булган аларның. Гади генә түгел, фронтовик укытучы! Җидееллык мәктәпне тәмамлап, Алабуга педучилищесына укырга кергән ул. 1941 елның 22 июнендә – Захаров укыган төркем аттестат аласы көнне иртүк каһәр суккан сугыш башланган. «Балалар, сугыш!» дигән сүз яшьләрнең өметен өзгән. Василийга 17 яшь тә тулмаган, шуңа күрә аны Краснобор районына башлангыч сыйныф укытучысы итеп җибәрәләр. Әлбәттә, озакка түгел. Сарапул хәрби-пехота училищесында алты ай укыгач, 1943 елда укытучы егетне Воронеж фронтына взвод командиры итеп билгелиләр. Василий Берлинга кадәр барып җитә. 1947 елда демобилизацияләнгәннән соң, башта туган авылы мәктәбендә хәрби җитәкче, аннан тарих укытучысы, директор урынбасары вазыйфасын башкара. Яшь укытучы Мариягә өйләнеп, гаилә кора. Хатыны авылдагы сабыйларны утыз елдан артык укырга, язарга, санарга өйрәтә. Василийга исә дүрт ел Морт районында халык мәгарифе җитәкчесе дә булырга туры килгән. 1954 елдан 1965 елга кадәр Олы Шүрнәк мәктәп директоры вазыйфасын башкарган. Колхоз рәисе итеп билгеләсәләр дә, күңеле барыбер укытучылыкка тарткан. Тарих укытуын дәвам иттергән. Төрле дәрәҗәдәге медальләр белән бүләкләнгән. 85 яшендә вафат булган.

Гомумән, бу нәселдә мактау кәгазе алмаган укытучы юк. Барысы да хөрмәткә лаек.

Василий белән Мария укытучы һөнәренә мәхәббәтне улы Борис һәм кызы Татьянада да уята алган. Татьяна 34 ел гомерен мәктәпкә багышлый. Борис та, әтисе кебек, гомерлек яры итеп башлангыч сыйныф укытучысы Равиләне сайлый. Алар Олы Шүрнәк авылы балаларын гыйлемле итүгә зур өлеш кертсән. Борис абый 45 ел физика укыткан, мәктәпне җитәкләгән. Өч бала үстергән алар. Олы уллары Руслан заманында физика укыткан, әмма хәзер геофизик булып эшли икән. Кызлары Лариса Осипова – хәзерге вакытта Алабугадагы 7 нче мәктәптә директор урынбасары. Төпчекләре Вадим techin pedinstitute...

Нәселдәге барлык укытучыларны да санап бетерерлек түгел. Арада гомер буе укытучы булып эшләгәннәре дә, шул ук вакытта башка юлдан китүчеләре дә бар. Василий Захаровның сеңлесе Вера Мельникова турында да әйтмичә булмый. Ни өчен дигәндә, нәселнең әлеге тармагы Иске Куклюк мәктәбенә хезмәт итә. Вера ханым 26 ел башлангыч сыйныфларны укыткан. Аның улы Иван 41 ел мәктәптә директор булып эшләп, лаеклы ялга чыккан. Ә хатыны Валентина хәзер дә татар теле укыта. Уллары Николай да әти-әнисе сукмагын сайлаган. Биредә 13 ел тарих укыта.

Без әлеге нәселдәге өченче буын укытучы – Лариса Осипова белән элемтәгә кердек.

– Кечкенә чакта көзге артына акбур белән язып, укытучы булып уйнадым, ә Василий бабам хаталарны тикшерә иде. Укытучы булыгыз дип үгетләгәнен хәтерләмим, – ди 45 яшьлек Лариса Борисовна.

Нәселе белән горурлануын да яшермәде ул. Әти-әнисе, туганнары – эшендә дә зур терәк. «Бергә җыелган чакта да сүзебез эшкә барып тоташа. Элеккеге белән хәзергене чагыштырып, фикер алышабыз. Олы буын: «Сезгә рәхәт, интернеттан бөтен нәрсәне табып була, ә без үзебез эзли идек», – ди. «Ничек эшләсәк, дөрес булыр?» – дип киңәшләр дә сорыйбыз. Алар заманча карашлы, бүгенге мәктәптә акбур тотып та, шул ук вакытта интерактив тактада да менә дигән итеп эшли белә. Үзем дә акбур белән эшләргә яратам», – ди Лариса.

Әти-әнисе Ларисаны баштарак укытучы булмаска өндәсә, хәзер, берүк китә генә күрмә, дип тора икән. ЗАГСка китеп эшләп караган, әмма барыбер укучыларын сагынып, кире мәктәпкә кайткан. Белемле физик, математик әби-бабай булганда, оныкларга да рәхәт. Репетитор яллыйсы юк.

Оныклар, оныкчыклар укытучы эшен дәвам иттерерме соң? Анысы билгесез. Әйтик, Борис абый белән Равилә апаның сигез оныгы бар. Барысы да – ир-егетләр. «Ирләрнең бик укытучы буласы килми шул. Әмма арадан 1–2се булса да безнең юлдан китсә, бик сөенер идек», – ди Захаровлар.

Сәрия МИФТАХОВА

ЛАПАСТАГЫ БАЙЛЫК

15 АВГУСТ – АРХЕОЛОГЛАР КӨНЕ

Без бел(мә)гән тарих

Сүзебез – ишегалдындагы корылма түгел, ә Әстерхан өлкәсендәге татар авылы Лапас турында. Соңгы араларда монда бик җитди казу эшләре бара. Хәзинә эзләүчеләр – Казан федераль университеты белән Татарстан Фәннәр академиясенең Археология институты белгечләре, студентлар. Экспедиция Татарстан Республикасының «Татар халкының милли тәңгәллеген саклау» программасы кысасында үткәрелә.

Казу эшләре вакытында археологлар Алтын Урда чорында, 1320–1330 нчы елларда төзелгән шәһәрчек-каберлеккә юлыкканнар. Бу – шәһәр тибында төзелгән бик зур татар зираты, ди алар.

– Без әлеге археологик һәйкәлне «Патшалар үзәнлеге» дип атау ягында, чөнки монда Алтын Урда (элегрәк аны үзара Ак Урда дип тә атаганнар) дәүләтенең җитәкчеләре һәм югары дәрәҗәдәге түрәләре җирләнгән дип фаразлана. Үзбәк хан тарафыннан монда дини-сәяси үзәк төзелгән булырга тиеш, – ди бу җәһәттән тарих фәннәре кандидаты Ришат Гузейров.

Бу каберлек-шәһәрчекне төзүче осталар өч чакрым ераклыкта, Актүбә елгасы буенда яшәгәннәр. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, алар кирпеч белән известьне Алтын Урданың төрле төбәкләреннән коры җирдән дә, су буйлап та ташыганнар. Мондагы төзелеш материаллары инде күпне күргән археологларны да шаккатырган. Баксаң, моңа кадәр аларның бу дәрәҗәдә югары технология белән эшләнгән кирпечне беркайчан да очратканнары булмаган. Ул үзе составы ягыннан табигый ак ташка охшаган, фаянс әзерләгән вакытта кулланылган технология белән яндырылган.

Үзәк мавзолейның биеклеге – 50 метр, стеналарның калынлыгы – 2 метр. Гөмбәзе зәңгәрсу төстә. Алгы ягындагы бизәкләр чәчәк һәм үсемлекләрдән ясалган. Бу мавзолей хаҗ урыны булып саналган. Алтын Урданың барлык төбәкләреннән изге урынга халык агылган. Сарай-Бату дип аталган башкала да шәһәрчектән 50 чакрым ераклыкта гына урнашкан булган.

Тикшеренүләр вакытында студентлар мавзолей эчендәге өч каберлеккә юлыкгалар. Берсендә 7–8 яшьлек малай җирләнгән. Галимнәр фикеренчә, калган икесендә дәүләт элитасы төркемәнә кергән өлкән яшьтәге кешеләрнең җәсәдләре булырга тиеш. Җирле халыкның элек-электән килгән үз фикере бар: алар үзәк мавзолейда Дәүләт-Хан җирләнгән дип уйлыйлар. Шунда ук агач кисәкләре дә табылган. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, алар мавзолей һәм җылылык үткәрү системасы төзелешендә кулланылган. Бу система температура кискен үзгәргәндә бинаны җимерелүдән саклаган.

Археологлар әйтүенчә, каберлек-шәһәрчектә төрле зурлыктагы мавзолейлар, каберләр бик күп. Аларның сурәтләре Урта Азиядәге мавзолейларга охшаган. Димәк, эшләгән осталар да шул яклардан килгән дип фараз кылырга була. Әлбәттә инде, моның дөреслеген дәлилләр өчен борынгы Хәрәзмдәге корылмалар өчен кулланылган плитәләрнең составын өйрәнергә туры киләчәк. Һәр табылдыкка шунда ук паспорт ясала. Хәзинәләрнең барысы да Татарстан Республикасының археология музеена тапшырылачак.

КФУ доценты Рузил Саттаров әйтүенчә, экспедициядә археолог белгечлеген сайлаган студентлар да, магистрантлар да катнаша. «Без лекцияләрдә алган белемнәрне хәзер практикада кулланабыз, археологик эшләр үткәрүнең методикасы белән танышабыз», – ди ул.

Әйтергә кирәк, борынгы каберлек археологлар өчен генә түгел, башка өлкәдәге белгечләр өчен дә кызыклы. Мәсәлән, монда палеоботаника (ягъни казу эшләре барышында табылган, борынгы заманга бәйле үсемлекләрне өйрәнү) буенча да тикшеренүләр бара. Физика институтының астрономия һәм геодезия кафедрасы вәкилләре топография сурәтләре төшерү белән мәшгуль.

Чөнки объектның кайда урнашуын, нинди формада булуын ачыклау бик мөһим. Бу соңыннан компьютерда корылмаларның моделен ясау өчен кирәк. Географ белгечлеген алырга җыенучылар туфрак составын, җирле флора һәм фаунаны өйрәнәләр. Зәңгәрсу төскә манылган кирпечләрне Казанга алып кайтып тикшерәчәкләр. Кыскасы, тарих ул – шундый әйбер: аның төпкеленә төшәргә дип казына башласаң, һәркемгә дә эш җитәрлек.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

1367 елда бу мавзолей Италия сәяхәтчесе Пицигани картасына кертелгән була.

Ватан хакына

УЛЫН КӨТҮЧЕ АНА:

«Яшәмәгән көннәр була»

Әлки районының Түбән Әлки авылында яшәүче Наилә Сираҗиева улының махсус хәрби операциядән җиңү белән кайтуын көтә. «Көтү өмет бирә, кабат озату кыен», – ди ул. Әле шушы көннәрдә генә ялга кайткан улын озаткан.

Улы Айратның китәсен белгәч, башта бик борчыла әнисе. Бер мәлгә бөтен тормышын күз алдыннан уздыра ул. Ичмасам, әтиләре дә исән түгел, дип уфтана.

– Ирем Рияз бик акыллы иде. Бергә озак яшәп кенә булмады. 2014 елның 24 маенда эштән кайтты да йөрәк белән китеп барды. Шул вакытта Айратны армиягә чакырып повестка килде. Әллә көзгә калдырыйкмы, диештек, тик үзе китәргә теләде. Үз сүзендә тора торган, әйткән сүзен үти торган бала ул. Бу юлы да: «Чакыргач, барам», – диде, – дип сөйли Наилә апа.

Наилә апа олы улы гаиләсе белән яши. Өйдәге улы белән киленен гел мактап тора. Алар, әниләрен ялгыз яшәтмәс өчен, шәһәрдән авылга күченеп кайтканнар. Кода-кодагыйлар гел ярдәм итеп тора. Бөтен эшне бергә эшлиләр икән. Алар барысы да бер теләктә хәзер: Айратлары исән-имин әйләнеп кайтсын!

– Улым ялга кайткандагы рәхәт хисләрне белсәгез иде! Бик сагынып көттем. Кадерләп үстергән ике алтын бөртегем бит алар. Айрат беренче көннәрдән үк шунда бит. Бик авыр яраланган да иде әле. Госпитальдә ятып чыкты. Ул чакта ике дусты үлде, улым яраланды. Әле хәзер дә шул егетләрне юксына, оныта алмый. Безнең районныкы иде алар. Ялга кайткач, беренче эш итеп, алар каберенә барды, – ди Наилә апа. – Ул хәзер дә алгы сызыкта. Ике көнгә кертәләр. Шул ике көндә яшәмибез инде без. Өйдә тынлык. Тамактан азык үтми, күзгә йокы керми. Улым исән булуын хәбәр иткәч кенә, тормыш җанлана...

Әнисе улын, монда кайткач, тәмле ризыклар белән сыйлаган. Мараты – мантый, Айраты өчпочмак ярата икән. Әниләре гомер буе бертөрле эчлек әзерләп, ике төрле камыр баса шуңа.

– Улым бер дә зарланмый. Гуманитар ярдәм җибәрүчеләргә рәхмәтләрен әйтә. Күчтәнәчләр килгәч, күңелгә рәхәт була инде, ди. Балаларын көтүче әниләргә сабырлык телим. Гел догада булыгыз. Ана догасы кабул булмый калмас, – ди Наилә апа. – Түземлек кирәк. Бәргәләнеп, елап, үксеп, берни үзгәртеп булмый. Батыр йөрәкле уллар үстерә алганбыз икән, инде аерылып торуга гына түзә алыйк! Балаларны фәрештәләр сакласын!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Рәсми хәбәр

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Чыпчык авыл җирлегендә (кадастр кварталы 16:16:181301) урнашкан күчемсез милек объектларына карата 06.03.2023, № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Биектау районы, Чыпчык авылы, Совет ур., 10б й. (телефон: +7 (84365) 3-29-89) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 8 сентябрендә (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: ТР, Биектау районы, Чыпчык а/ж, Чыпчык авылы, Совет ур., 10б й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 17 августыннан 2023 елның 8 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 8 сентябреннән 2023 елның 14 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Тәфсилле мәгълүмат сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Авыл хәлләре

Күпер башында... кич утыру

Авылларда хәзер капка төпләренә җыйналып кич утыру, авыл, дөнья хәлләре турында гәпләшү гайре табигый хәлгә әйләнеп бара. Аны инде көн саен, кич саен түгел, бәйрәм рәвешендә ясап, чакырып кына үткәреп, оештырып була. Кызык та, кызганыч та.

Капка төпләрендәге эскәмияләр күптән туздылар, яңалары, заманчалары күбесенчә ишегалларында, бакчаларда урын алды – алар хәзер авылларда капка төпләрендә бик сирәк очрый. Менә шуннан да бүгенге авыл хәлен күзаллап була инде.

Балтач районының Чутай авылында яшәүче күптәнге танышым Гөлзифа шушы көннәрдә шатлыгы белән уртаклаша: «Биш ел элек хыяллана башлаган идем, беренче елны оешып җитә алмадык, аннан коронавирус булды, аннан... Быел, ниһаять, үзебезнең күпер башында кич утыру оештыра алдым бит», – ди. Күпер башы дигәч тә, күпер өстенә барып кич утырмаганнар икән.

– Авылның безнең очы күпер башы дип йөртелә. Анда алты хуҗалык. Без электән бик тату, дус яшәдек. Әмма соңгы вакытта җыйнаулашып кич утырулар бездә дә беткән иде. Быел әрәпә җыйганда, урамыбыз белән мәш килеп, бик матур итеп табыннар корып, капка-коймаларны бизәп, «уянып» алган идек инде. Күпер башы бәйрәме үткәрик әле, дигәнемне дә бөтенесе күтәреп алды. Читкә киткәннәрне, шушында туып-үскән бөтен кешене чакырдык. Кайта алганнар кайтты. Кырыктан артык кеше җыйналдык. Өлкәннәр, яшьләр, балалар. Ул көнне әле авылда туй иде, урамыбыздан 7–8 кеше туйда калды. Искиткеч күңелле бәйрәм булып чыкты. Алдан бер атна шул бәйрәм турында сөйләштек, бәйрәм көнендә кич буе бөтен истәлекләрне, берсеннән-берсе күңелле хәлләрне искә алдык, бик күп хатирәләрне яңарттык, – дип сөйли Гөлзифа.

Мич коймагы белән дә сыйланганнар, пылау да пешкән, шашлык та өлгергән, самавырлар кайнаган... Җырларга, биергә дә өлгергәннәр (әле бит күпме хатирәләрне дә барлаганнар). Ә без һаман, вакыт җитми, дибез. Анысына да, монысына да өлгермибез. Юкса шушындый очрашуны үткәрү өчен ике-өч сәгать вакыт кирәк булган.

Кем белә, бәлки, шушындый бәйрәмнәр бездә кабат авыл гамен уятырга сәләтледер? Бер үтәр, ике үтәр дә аннан көндәлек кич утыруга әйләнер? Эскәмиясез, кешеләрсез авыл урамнары буйлап үткәндә дә өметне өзәсе килми шул.

Сүз уңаеннан, күршелекнең дәрәҗәсе дә, чикләре дә юк иде элек. Ихласлык кына бар иде. Хәер, бу кадәресе хәзер дә кешенең үзенә бәйле икән бит. «Урамыбызда яшәүче хуҗалык рәисе Фердинанд Хәйруллин да – безнең өчен, күпер башлары өчен гапгадәти күрше. Әрәпә җыйганда үткәргән бәйрәмдә дә, монысында да гаиләсе белән башыннан азагына кадәр безнең белән бергә булды», – ди Гөлзифа. Алар инде аның гадилеген болай да белә. Гаҗәпләнеп, аптырап әйтми. Мин дә бу кадәресе, бәлки, кемнәргәдер уйлану өчен бер сәбәп булыр, дип яздым.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

БОРЫЛА ДА КИТӘ БОЛЫТ

Һава торышы

Атна ахырына Идел буе төбәкләрендә һава температурасы төшәчәк. «Фобос» үзәге белгече Михаил Леус хәбәр итүенчә, атна ахырында Татарстанда да көчле яңгыр һәм яшен көтелә.

Шушы көннәрдә Идел буеның төньяк өлешенә салкын атмосфера фронты килә. Шул сәбәпле, кыска вакытлы яңгырлар да яварга мөмкин. Әлеге салкын атмосфера фронты көньяк өлешкә бераз соңрак киләчәк. Казанда исә бу көннәрдә яңгырлар явачак, тик һава температурасы төшми, 27–30 градус эссе була. Атна ахырына гына 25 градус көтелә.

Казан федераль университеты профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев исә, антициклон хакимлек итү аркасында, Татарстанга яңгырлар килеп җитә алмас, дигән фикердә. «Яңгыр болыты Мәскәүгә килеп җитә дә борылып китә. Безгә килми ул. Антициклон җибәрми. Эсселәр дәвам итәчәк әле», – ди профессор.

Ә менә Балтач районының Яңгул авылында яшәүче халык синоптигы Әмир Шәрәфиев атна башында ук яңгыр көткән. «Киләсе атнадан һава температурасы бераз төшәчәк. Хәзер бит төннәр озыная, салкыная. Шунлыктан һава җылынып бетәргә өлгерми. Әмма сентябрьдә көннәр җылы торачак», – ди халык синоптигы.

Без аның кышка фаразларын да белештек. Суган кабыгына гына ышана торган заман бетте, ди ул.

– Суганның да төрле сорты бар. Кайберләре бик калын кабыклы, кайсысы юка. Әнә шуңа да иң ышанычлы халык сынавы – чикләвек уңышы инде. Әгәр ул күп булса, кыш салкын килер. Әлеге урманга барганым юк. Әмма үз фаразларым буенча, быел кыш җылы булмас. Ноябрь ахыры – декабрь башы салкын булачак, аннары бераз җылытыр. Гыйнвар ахырында кабат салкыннар кире кайтачак, – дип фаразлый ул.

Сүз уңаеннан, Татарстанның гидрометеоүзәге, яңгыр вакытында җил секундына 20 метр булырга мөмкин, дип тә кисәтә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«ТАТНЕФТЬ» – ЭТНОМӘДӘНИЯТ САГЫНДА

Вакыйга

14 июльдән 6 августка кадәр Әлмәт шәһәре кабат этно-модерн үзәгенә әйләнде. Шушы вакыт аралыгында һәр шимбә һәм якшәмбедә күпләр яратып өлгергән һәм зур түземсезлек белән көтеп алган Karakuz фестивале гөрләде. Чараның оештыручысы – «Татнефть» компаниясе быел кунакларны нәрсә белән сокландырды һәм рухландырды? Үзебез күреп кайттык.

Кызыклы проектлар өчен мәйдан

Билгеле булганча, фестиваль быел өченче тапкыр уздырылды. «Татнефть» быел да һәркемнең күңеленә барып җитәргә тырышкан, һәр кунак үзен кызыксындырган юнәлешне таба алсын өчен барысын да эшләгән. Бу көннәрдә шәһәрнең төрле урыннарында кунаклар өчен этник, хореографик, джаз, юмор, театр, китап һәм яшьләр фестивалендә катнашу, шулай ук спектакльләр һәм кинолар карау, рәсем сәнгате буенча остаханәләрдә катнашу мөмкинлеге тудырылган иде. Шунысын да әйтергә кирәк: фестиваль татарстанлыларны гына түгел, Россиянең төрле төбәкләре һәм якын чит илләр вәкилләрен дә җәлеп итүе белән кадерле.

Әйтик, беренче көннәрдә күпләрдә зур кызыксыну тудырган «Этномаркет» ярминкәсендә һөнәрчеләр иҗаты белән танышырга мөмкин иде. Тимерчеләр, тегүчеләр, чигүчеләр, күн ясаучылар, үләнчеләр, чүлмәкчеләр үзләренең кул җылысы кергән эшләнмәләрен генә тәкъдим итеп калмыйча, мастер-класслар да бирде. «Аулак» мәйданында Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан һәм Әлмәт иҗатчылары перфомансларын, мастер-классларын һәм спектакльләрен тамаша кылырга мөмкин иде. Шулай итеп фестиваль заманча мәдәни тормышның күпкырлы кыйпылчыкларын бер казанга җыярга булышты.

– Фестиваль әлмәтлеләрдә генә түгел, башка шәһәрләр һәм төбәк вәкилләре арасында да елдан-ел зуррак кызыксыну уята. Катнашучылар саны да артканнан-арта бара. Бу – безнең өчен зур күрсәткеч, – диде «Татнефть» грантлары» программасы җитәкчесе Эльмира Газизова.

Быелгы фестивальнең яңалыгы төп игътибарны экологиягә юнәлтүдән гыйбарәт. Әйтик, Karakuz кысасында узган «Кладовка» экофесты кулланылган әйберләрнең кадерен арттырырга ярдәм иткән. Әлеге мәйданчык кунаклары калдыкларны сортларга аерырга, шеринг (матди һәм матди булмаган кыйммәтләр белән бүлешү) икътисадының асылына төшенергә, ватык тәлинкә кыйпылчыкларыннан түштамгалар ясарга өйрәнгән.

Китап фестивале

Безгә исә фестивальнең соңгы көннәрендә узган китап ярминкәсен күрергә насыйп булды. Быел беренче генә тапкыр уздырылса да, басма сүзнең кадерен һәм кыйммәтен аңлаган китап сөючеләрнең күңеленә тәгаен хуш килгән чара булды ул.

Китап фестивален оештыручылар – «Татнефть» компаниясе һәм Казанның «Смена» заманча мәдәният үзәге – китапның әле дә үз кыйммәтен югалтмавына чын күңелдән ышануын белдерде һәм моны раслады да. Китап яхшы дус та, акыллы киңәшче дә, төпле сердәш тә, сабыр укытучы да була белә, ди алар. Әлеге форум Казанда ун ел элек оештырыла башлаган иде. Шушы вакыт эчендә ул тугры китап сөючеләрне генә түгел, ә Россиянең иң кызыклы, көчле нәшриятларын да үз канаты астына җыя алды. Бу көнне дә укучыларга әле яңа гына типографиядән чыккан, буяу исе аңкып торган басмаларны кулларына алу бәхете елмайды.

Заманча мәдәният, сәнгать, музыка, театр һәм кино, психология, фәнни-популяр һәм балалар әдәбияты. Фестивальгә килүче һәркем күңеленә хуш килгән басманы таба алды.

Балалар өчен иҗат итүче классик авторларның әсәрләрен заманчалаштырып бастыручы Мещеряков йорты нәшрияты исә фестивальгә әле беркайда да сатылмаган эксклюзив басмаларын алып килгән иде.

– Без фестивальдә беренче тапкыр Казанда узган вакытта катнашкан идек. Быел менә Әлмәткә килү мөмкинлеге туды. Китап укучы дусларыбызга яңа эксклюзив басмалар алып килдек. Алар әле китап киштәләрендә дә юк. Без әлеге китапларны арзанрак бәядән тәкъдим итәбез. Әлмәттә укырга яратучан халык яши икән. Безнең өчен укучыларыбыз белән аралашу, үзебез турында сөйләү дә мөһим. Китапларыбыз белән кызыксыну зур булуына чын күңелдән сөендек. Димәк, без дөрес юлда, – ди нәшрият вәкиле Даниил Безуглов.

Чыннан да, алар яныннан зурлар да, балалар да өзелмәде. Тукталган һәркайсы үзе белән тәмле «күчтәнәч»ен дә кыстырып китте. Даниил Безуглов фикеренчә, замана укучысына актуаль темаларга аңлаешлы тел белән язучы яхшы Россия авторлары кирәк. Ул әсәрләрдә укучы үзен танырга тиеш: бәлки үзен яки әйләнә-тирәне өйрәнәдер, бәлки ил буйлап сәяхәт итәдер, бәлки башы-аягы белән фән дөньясына чумгандыр. Һәм китап киштәләрендә үз урыннарын тапкан күпчелек китап авторы бу максатка ирешә дә, ди ул.

– Заманча авторныкынмы яки классик язучыларның әсәрләрен кабат бастырумы – алар барысы да заманча иллюстрацияләр белән бизәлеп, эксклюзив итеп эшләнелә, – дип тә өстәде.

Ярминкәгә балалар, яшүсмерләр һәм аларның әти-әниләре арасында популяр булган тагын бер нәшрият – «Самокат» та килгән.

– Фестивальдә катнашуыбызга бик шатбыз, – диде нәшрият вәкиле Елена Титова. – Күп тапкырлар Казанда булсак та, монда беренче тапкыр. Без Татарстан укучылары янына яратып киләбез. Бүген дә кешеләр белән аралашкан вакытта безне белүләрен, тануларын, китапларыбызның интернеттан заказ биреп укуларын, әсәрләрнең дәвамын көтүләрен белгәч, күңелне әйтеп бетергесез рәхәтлек хисе биләп алды. Шуның өчен бу чара безнең укучыларыбыз белән танышу түгел, ә иске дуслар белән очрашу булды.

Фестивальнең йөзек кашы

Мәскәүдән «Карьера-пресс» нәшрияты вәкиле Ольга исә балаларга хисләр өермәсе бүләк итте – ул эмоцияләр турында мастер-класс уздырды.

Билгеле, әлеге ярминкәне Россиянең иң кызыклы, көчле нәшриятлары гына түгел, укучылар да көтеп алган иде. Зур гына сумкасын китаплар белән тутырган Элиза Григорьева да әнә шулай диде.

– Мин бу күргәзмәдән бик канәгать калдым, – диде ул. – Барысы да уйланылган. Күреп торасыз: 7 һәм 8 яшьлек оныкларыма күп итеп китаплар сатып алдым. Үзем өчен дә китап эзләгән идем. Тик анысын монда тапмадым. Киләсе елга алып килергә вәгъдә иттеләр. Димәк, кабат килер өчен сәбәп бар!

«Смена» программалары кураторы Александр Григорович сүзләренчә, фестивальдә 30 бәйсез нәшриятның китаплары тәкъдим ителде.

– Монда мәдәният тә, фән дә, сәнгать тә бар. Аларның һәркайсы Әлмәт укучысына ниндидер яңалык алып килде. Иң мөһиме – китаплар кибет бәясеннән арзанрак хакка сатылды. Белем бирү программасы да кызыклы лекцияләргә бай булды, – диде ул.

Чыннан да, ике көн дәвамында барган белем бирү программасында тарих, мәдәният, фән турында лекцияләр сөйләнде, Россия язучылары һәм галимнәренең китаплары тәкъдим ителде, төрле тематикадагы документаль фильмнар күрсәтелде. Әйтик, «Теория моды» журналының шеф-редакторы Людмила Алябьеваның моданы өйрәнү буенча лекциясен яшьләр дә, өлкәннәр дә кызыксынып тыңлады. Кызыксындырган сорауларын да күпләп бирделәр.

Әлбәттә инде, фестивальнең йөзек кашы кабат бастырылган «Танбатыр. Баллада о нефтянике» китап-картинкасы иде. Балалар белән бергә нефть төбәгенең тарихын өйрәнеп була торган китап – язучы Әдип Маликов белән рәссам Ирина Колмогорцеваның уртак иҗат җимеше. Еллар узса да, китапның эчтәлеге үзенең актуальлеген югалтмаган. Яңа сулыш өрелгән басманы «Каракүз» фестивале өчен махсус бастырганнар. «Танбатыр. Баллада о нефтянике» китап-картинкасы теләге булган һәркемнең киштәсенә фестиваль бүләге буларак кайтып китте.

Фестивальгә исә Әлмәт комлыгында оештырылган джаз концерты белән нокта куйдылар. AJC-band джаз-ансамбле, Анна Бутурлина, Петр Востоков и Большой джазовый оркестр, Shanyana & Guru Groove Foundation, Александр Чумаков – һәр башкаручы ул көнне тыңлаучылар күңеленә үз ачкычын таба алды.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

Фото: «Татнефть» җәмгыяте мәгълүмати сәясәт идарәсе

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5129 данә
Гомуми тираж – 14057 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 316

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+